ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июнь 2020 ел №25

«2015-2030 елларга «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару схемасын раслау турында» 2015 елның 29 апрелендәге 26 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы, «Ташландык суларны чыгару (канализация) үзәкләштерелгән системаларын җирлекләрнең һәм шәһәр округларының ташландык суларны чыгаруүзәкләштерелгән системаларына кертү кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 сентябрендәге782 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 31 маендагы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2015-2030 елларга «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару схемасын раслау турында» 2015 елның 29 апрелендәге 26 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең «Балтач шәһәр тибындагы поселогының ташландык суларны чыгару елкәсендә гамәлдәге торышы» 3.1 пуктын түбәндәге эчтәлекле 3.1.10 пунктчасы белән тулыландырырга:

«Ташландык суларны чыгару үзәкләштерелгән системаларын (канализацияне) җирлекләрне һәм шәһәр округларын ташландык суларны чыгаруүзәкләштерелгән системаларына кертү турында белешмәләр.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең ташландык суларны чыгаруүзәкләштерелгән системасына карата 2009 елның 31 маендагы 691 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының ташландык суларны чыгару(канализация) үзәкләштерелгән системаларын кертү кагыйдәләре белән билгеләнгән җирлекләрнең һәм шәһәр округларының ташландык суларны чыгару(канализация) үзәкләштерелгән системаларына кертү критерийларының җыелмасын үтәү тәэмин итеlә.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең

ташландык суларны чыгаруузэклэштерелгэн системасы авыл җирлеклэре һэм шэһэр округларының ташландык суларны чыгаруузэклэштерелгэн системаларына кере.».

2. Әлеге карарның гамэлдэ булуын 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгэн хокук мөнэсэбэтлэренэ кагыла дип билгелэргэ.

3. Әлеге карарны «Интернет» мэгълүмат-телекоммуникация челтэрендэ http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мэгълүматының рэсми порталында һэм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рэсми сайтында халыкка игълан итэргэ.

4.Әлеге карарның үтэлешен контрольдэ тотуны үз өстемэ алам.

Балтач шэһэр җирлеге
Башкарма комитеты җитэкчесе И. Д. Габдрахманов